КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 февраль

г.Казань

№ 72

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкәсе һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендәге стратегиягә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 4 июнь, 520 нче, 2022 ел, 9 июль, 661 нче, 2023 ел, 16 май, 597 нче, 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы, 2024 ел, 26 февраль, 96 нчы, 2024 ел, 2 сентябрь, 720 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегиягә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең «Бурычлар» юлына түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Цифрлы икътисад һәм ИТ-тармак өчен кадрларны системалы һәм баланслы әзерләүне оештыру»;

4 бүлекнең 4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 14 - 16 пунктчалар өстәргә:

«14. Федераль бюджетның һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укытуга кабул итүнең контроль саннары күләмнәрен арттыру.

15. Цифрлы икътисад таләпләре нигезендә белем бирү программаларын актуальләштерү.

16. ИТ-тармак ихтыяҗлары өчен белем бирү программалары исемлеген киңәйтү.»;

5 бүлекнең 1 бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 9 - 11 пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «9. | Икътисадны цифрлы трансформацияләү өчен югары технологияле кадрлар әзерләү максатында әзерләүнең һәм белгечлекләрнең ИТ-юнәлешләрен популярлаштыруга юнәлдерелгән мәгълүмати кампанияләрне гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасында ИТ-белгечлекләрне популярлаштыру программасы | Укучылар | Татарстан Республикасында урнашкан югары белем бирү оешмаларына һәм һөнәри белем бирү оешмаларына ИТ-белгечлекләр буенча укырга керүгә потенциаль абитуриентларның мотивациясен арттыру |
| 10. | Укыту программаларын формалаштыруда, житештерү практикаларын оештыруда, кадрларны дуаль әзерләүдә катнашу максатларында эш бирүчеләр вәкилләрен белем алу процессына җәлеп итү | Татарстан Республикасында ИТ-белгечлекләрне популярлаштыру программасы | Укучылар; дәүләт һәм коммерция оешмалары | ИТ-белгечләрне әзерләү системасын камилләштерү, оешмаларның кадрлар потенциалын үстерү |
| 11. | «Иннополис университеты» югары белем бирүче автоном коммерциягә карамаган оешмасының алдынгы инженерлык мәктәбе эшчәнлеген үстерү | «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проекты | Укучылар; педагогик хезмәткәрләр; дәүләт һәм коммерция оешмалары | Алдынгы инженерлык мәктәбе партнерлары булган югары технологияле компанияләрдә квалификацияне күтәрү, стажировка үткәрү. Инженерлык кадрларын алдан әзерләү буенча яңа программалар эшләү. Әйдәп баручы югары технологияле компанияләрдә остазлар белән практика узу»; |

6 бүлекнең 1 бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 14, 15 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «14. | Татарстан Республикасында ИТ-белгечлекләрне популярлаштыру программасы | Татарстан Республикасы икътисадын цифрлы трансформацияләү өчен югары технологияле кадрлар әзерләү | 2026 елга кадәр | Программа түбәндәгеләргә юнәлтелгән:<br><br>республикада ИТ-һөнәрләргә ихтыяҗ турында, югары белем бирү мәгариф программалары, урта һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) өстәмә һөнәри | Республика башкарма хакимият органнарының, мәгариф оешмаларының төп эшчәнлеге кысаларында | Проектны башкаручы төбәк |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | белем бирү програм-малары кысаларында ИТ-белгечлекләр буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнаш-кан мәгариф оешмала-рында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында федераль һәм (яисә) төбәк бюджетларның бюджет ассигнование-ләре исәбеннән уку мөмкинлеге, шулай ук ИТ-өлкәдә аннан соңгы карьера мөмкинлекләре турында Татарстан Республикасында граж-даннарга киң мәгълүмат бирү;<br>Татарстан Республика-сында гражданнарны ИТ-белгечлекләрне попу-лярлаштыруга һәм цифрлы икътисад өчен кадрлар әзерләүгә ярдәм итүче Россия Федера-циясе Фән һәм югары белем министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы-ның, Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм комму-никацияләр министрлы-гының профильле чараларында катнашуга җәлеп итү | | |
| 15. | «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проекты | Россия Феде-рациясе ик-тисадының югары җитештерүчән секторларын югары квали-фикацияле кадрлар белән тәэмин итү | 2025 елга ка-дәр | Инженерлык әзерлеге өчен кирәкле шартлар, алга киткән фәнни эшләнмәләр тәэмин итәчәк югары техно-логияле компанияләр белән партнерлыкта алдынгы инженерлык мәктәпләре булдыру | Федераль финанслау, Татарстан Республика-сы бюджеты | Төбәк югары белем бирү мәгариф оешмалары базасында алдынгы инженер-лык мәк-тәпләрен төзүдә һәм үстерүдә катнаша»; |

7 бүлекнең 1 бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 14 - 16 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «14. | Татарстан Республикасында ИТ-белгечлекләрне популярлаштыру программасы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укытуга кабул итүнең контроль саннарын алучы ИТ-юнәлешне гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмалары өлеше | % | 85 | 85 | 85 |
| | | | Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укытуга кабул итүнең контроль саннарын алучы ИТ-юнәлешне гамәлгә ашыручы урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары өлеше | % | 42 | 45 | 47 |
| | | | Федераль бюджетның һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча укытуның көндезге формасына кабул итүнең контроль саннары күләмнәрен арттыру динамикасы | % | 2,5 | 2,5 | 2,5 |
| | | | Оештырылган профориентация чаралары саны | берәмлек | 30 | 35 | 40 |
| | | | Профориентация чаралары белән колачланган гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өлеше | % | 30 | 30 | 30 |
| 15. | «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» федераль проекты | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы («Иннополис университеты» автоном коммерциягә карамаган югары белем бирү оешмасы белән берлектә (килешү буенча)) | «Иннополис университеты» автоном коммерциягә карамаган югары белем оешмасы базасында эшли торган алдынгы инженерлык мәктәпләре саны | берәмлек | 1 | 1 | 1 |
| | | | Инженерлык кадрларын әзерләү өчен инженерлык юнәлешендәге белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмаларының идарә итү командалары һәм профессор-мөгаллимнәр | кеше | 20 | 310 | 320 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | составы квалификациясен күтәрү һәм (яисә) яңадан һөнәри әзерләү курслары үткәрү (шул исәптән югары технологияле компанияләр базасында стажировка үтү рәвешендә) | | | | |
| | | | Магистратура программаларын үзләштерүче студентлар тарафыннан белем бирү процессы кысаларыннан тыш практика һәм (яки) стажировкалар узу, шул исәптән остазлар белән эшләү форматында | кеше | 8 | 10 | 10 |
| 16. | «Профессионалитет» федераль проекты | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, һөнәри белем бирү оешмалары | Проектта катнашкан һөнәри белем бирү оешмалары санын арттыру | берәмлек | 1 | 3 | 5»; |

8 бүлекнең 8.2 пунктында:

19 пунктчада «һәм фән» сүзләрен төшереп калдырырга;

27 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга чит илдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2024 ел, 28 август, 702 нче карары белән расланган «2024 – 2026 елларга чит илдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин